| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

27.08.2019 № 456-р

Нурлат муниципаль районында,
өлкән буын кешеләрен укыту максатыннан
"Өченче буын университеты" программасын
тормышка ашыру турында

Хокукларын һәм тормыш мәнфәгатьләрен яклау, «Демография» илкүләм проектын гамәлгә ашыру нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы пенсионерларын һәм пенсия яшендәге гражданнарны актив тормыш рәвешенә җәлеп итү, өлкән яшьтәге гражданнарга районның иҗтимагый һәм икътисадый тормышының төрле өлкәләрендә аларның социаль активлыгын арттыру, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән буын гражданнары мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясендә 2025кә кадәр гамәлләр стратегиясенең беренче этабын гамәлгә ашыру буенча 2017-2020 елларга чаралар планын раслау турында» 2016 елның 30 декабрендәге 3172-р номерлы күрсәтмәсе, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018-2020 елларга Татарстан Республикасында пенсия алды һәм пенсия яшендә яшәүчеләрне IT-технологияләр өлкәсенә җәлеп итү буенча республика планы турында», 2018 елның 14 августындагы 25-53/10626 номерлы расланган хаты белән

БОЕРЫК БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләре базасында «Өченче буын университеты» кысаларында, пенсия һәм пенсия яшенә җиткән затларны заманча белем нигезләренә укытуны оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л. М. Нәфыйгинага, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф һәм мәдәният бүлекләре начальникларына ведомство буйсынуындагы учреждениеләр базасында пенсионерларны һәм пенсия яшендәге гражданнарны укытуны оештыруда ярдәм күрсәтергә.

3. Россия Пенсия фондының Нурлат шәһәрендәге (районара) идарәсе җитәкчесе Р.М. Шакировага, Россия Пенсионерлар берлегенең Нурлат районындагы җирле бүлекчәсе рәисе Е. К. Савиновка «Өченче буын университеты»кысаларында, заманча белем нигезләренә укырга теләүче пенсионерлардан гаризалар кабул итүне оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф, мәдәният бүлекләре башлыкларына уку төркемнәре оештырырга, уку-укыту планын һәм программасын эшләргә, укытучылар төркеме оештырырга. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына курслар җитәкчесен билгеләргә һәм пенсионерлар белән дәресләрне үз вакытында үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 елның 27 августындагы 456-р номерлы
боерыгына кушымта

**«Өченче буын Университеты» турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Өченче буын университеты» (алга таба - Университет) - ул өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларның заманча таләпләргә җавап бирә торган социаль хезмәтләрдә ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән социаль хезмәт күрсәтүнең инновацион формасы, өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның ихтыяҗларын ачу буенча социаль хезмәтләр алуда аларны активлаштыру һәм үз-үзләрен тормышка ашыру максатында ярдәм итүне күздә тота.

1.2. Университет Россия Пенсионерлар берлегенең Нурлат районындагы иҗтимагый оешмасы базасында төзелә.

1.3. Үз эшчәнлегендә университет түбәндәгеләр белән җитәкчелек итә:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән буын гражданнары мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясендә 2025 елга кадәр гамәлләр стратегиясенең беренче этабын гамәлгә ашыру буенча 2017-2020 елларга чаралар планын раслау турында» 2016 елның 30 декабрендәге 3172-р номерлы боерыгы.

Россия Федерациясенең милли стандартлары:

- ГОСТ Р 52142 «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Социаль хезмәтләрнең сыйфаты»;

- ГОСТ Р 521443-2003 «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Социаль хезмәтләрнең төп төрләре»;

- ГОСТ Р 52496-2005 «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Социаль хезмәтләр сыйфатын контрольдә тоту»;

- ГОСТ Р 52497-2005 «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең сыйфат системасы»,

шулай ук әлеге тармакта хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив-хокукый актлар белән.

1.4. Университет җитәкчесе, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

1.5. Университет җитәкчесе университет эшен оештыра һәм координацияли, факультетлар эшчәнлеген контрольдә тота.

1.6. Университет үз эшчәнлеген Нурлат районы территориясендә төрле милек формасындагы оешмалар һәм хәйрия ярдәме күрсәтү, шулай ук университет эшчәнлеген тормышка ашыру өчен матди һәм матди булмаган ресурслар бирү белән кызыксынучы шәхси затлар (алга таба-партнерлар) белән тыгыз мөнәсәбәттә алып бара.

2. Университетның төп максатлары һәм бурычлары

2.1. Университет эшчәнлегенең төп максатлары булып:

- өлкән яшьтәге кешеләрнең тулы канлы һәм лаеклы тормышы өчен шартлар тудыру;

- өлкән яшьтәге гражданнарның иҗади потенциалын активлаштыру һәм аларда тормышка карата уңай мөнәсәбәт саклап калу;

- өлкән яшьтәге кешеләрнең аралашу мохитен формалаштыру һәм үстерү;

- өлкән яшьтәге кешеләрнең мәгълүматлылыгын һәм грамоталылыгын арттыру;

- өлкәннәрнең сәламәтлек дәрәҗәсен һәм физик активлыгын күтәрү тора.

2.2. Университетның төп бурычлары булып тора:

- өлкән яшьтәге кешеләргә хәзерге тормышка уңышлы адаптацияләү, үзлектән белем алу һәм аны камилләштерү өчен уңайлы шартлар тудыру;

- өлкән яшьтәге кешеләрне иҗади һәм социаль активлык өлкәсенә тарту;

- өлкәннәрнең коммуникатив күнекмәләрен арттыру;

- өлкәннәргә заманча техник чаралар һәм мәгълүмати технологияләр үзләштерүдә ярдәм итү;

- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

- өлкәннәр белән агарту эшчәнлеген оештыру өчен ветераннар, дини, иҗтимагый һәм башка оешмалар белән даими эшлекле контактларга булышлык күрсәтү;

- өлкәннәр проблемаларына җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итүгә юнәлдерелгән закон белән тыелмаган башка төр эшчәнлек төрләре.

## 3. Хезмәт күрсәтү шартлары

3.1. Университетка пенсия яшендәге гражданнар (50 яшьтән өлкәнрәк хатын - кызлар, 55 яшьтән өлкәнрәк ир-атлар) (алга таба-тыңлаучылар), факультетның исемен күрсәтеп, тыңлаучының шәхси язма гаризасы нигезендә, тиешле белемнәргә, осталыкларына һәм күнекмәләренә ия булу өчен сайлап алынган (кушымта) кабул ителә.

3.2. Тыңлаучы берүквакытта берничә факультетка йөри ала.

3.3. Университет тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәтләр өчен түләү Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

## 4. Университет эшен оештыру

4.1. Университет җитәкчесе мөстәкыйль рәвештә университет эшчәнлеген оештыра, планлаштыра һәм тормышка ашыра.

4.2. Учреждениенең штаттагы белгечләре белән беррәттән, уку-укыту процессын волонтерлык шартларында проектка җәлеп ителгән төрле оешма һәм учреждениеләр хезмәткәрләре һәм белгечләре башкара ала.

4.3. Университет эшчәнлеген алып бару өчен кимендә 4 кеше составында Университет Советы төзелә, ул Башкарма комитет карары белән раслана.

4.4. Университет үз эшчәнлеген берничә юнәлеш буенча (алга таба-факультетларда) алып бара:

- компьютер белеме факультеты;

- физик активлык һәм сәламәтлек факультеты.

4.5. Һәр юнәлешкә керүче дисциплиналар саны һәм составы университет тыңлаучылары ихтыяҗларыннан һәм учреждениенең ресурсларыннан бәйле.

4.6. Дәресләрне үткәрү формалары: лекцияләр, семинарлар, экскурсияләр, тренинглар, практикумнар һ. б. Дәресләр төркемле формада да, индивидуаль формада да үткәрелә ала.

4.7. Университетка укырга керү учреждение директоры боерыгы буенча гамәлгә ашырыла.

4.8. Университет җитәкчеләре тарафыннан, расланган эш номенклатурасы нигезендә исәп-хисап документлары алып барыла.

4.9. Университетта дәресләргә йөрү сертификатлар, дипломнар яки башка төр белем алу турында белешмәләр алуны да күздә тотмый.

4.10. Уку программаларына таләпләр:

4.11. Факультетларның уку-укыту программасы заманча нәтиҗәле ысулларга һәм укыту формаларына, белемнәрне контрольдә тотуга йөз тота.

4.12. Укыту программасы үз эченә ала:

- тыңлаучының башлангыч белем дәрәҗәсен, аның шәхси үзенчәлекләрен һәм һәвәслеген билгеләргә мөмкинлек бирүче кереш тестлаштыру ;

- укыту максатларына туры килә торган сайланган юнәлештәге теоретик дәресләр блогын;

- алган белемнәрне практик куллану күнекмәләрен алырга ярдәм итә торган гамәли дәресләр блогын үз эченә ала.

Уку формасы һәм режимы уку максатларын һәм срокларын исәпкә алып билгеләнә.

4.13. Укыту планы:

- укыту максатын;
- укуның дәвамлылыгын;
- дәресләр режимын;
- дәресләр буенча сәгатьләр санын үз эченә ала.

4.14. Уку-укыту программасы:

-кереш өлешне;
- темалар исемлеген;
- темаларның һәм бүлекләрнең реферативм тасвирламасын;
- һәр тема буенча дәрес төрләре исемен;
- укыту программасын тормышка ашыру буенча методик тәкъдимнәрне;
- кулланыла торган әдәбият исемлеген күздә тота.

4.15. Факультетларның уку-укыту программасының эчтәлеге карала һәм ул университет Советы тарафыннан раслана.

## 5. Тыңлаучының хокуклары һәм бурычлары

5.1. Тыңлаучы университет турында нигезләмәне үтәргә бурычлы.

5.2. Тыңлаучы университетның ярдәм һәм яклавыннан файдаланырга; университет эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга хокуклы.

5.3. Тыңлаучы, алдан университет җитәкчесенә хәбәр итеп, теләсә кайсы вакытта университетта дәресләр һәм чараларга йөрүне туктатырга мөмкин.

5.4. Әгәр дә тыңлаучы Университет җитәкчесенә дәресләргә йөрүне туктату турында хәбәр итмәгән һәм дәресләргә 1 айдан артык йөрмәгән очракта, җитәкче әлеге гражданны университет тыңлаучылары арасыннан төшереп калдырырга хокуклы.